ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04 декабрь 2024ел

№ 8115

Башкарма комитетның 2023 елның 2 июнендәге 4667 номерлы Карары белән расланган җир участоклары бирмичә һәм сервитут, җәмәгать сервитуты билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җир участокларында объектлар урнаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җирләрдән яки җир участокларыннан файдалануга рөхсәт бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 27 ноябрендәге 1244 номерлы Карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 3 декабрендәге 1300 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» 2023 елның 14 декабрендәге 2147 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдә яки җир участокларында, җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар, җәмәгать сервитуты билгеләмичә, төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 елның 5 июнендәге 416 номерлы Карары белән расланган Дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдә яки җир участокларында җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар, җәмәгать сервитуты билгеләмичә, төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 26 апрелендәге 278 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2023 елның 2 июнендәге 4667 номерлы Карары белән расланган җир участоклары бирмичә һәм сервитут, җәмәгать сервитуты билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җир участокларында объектлар урнаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5.1 пунктның 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: